РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ — КАРАР

№ 19 — 2020 елның 16 октябре

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30-32 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Майская Горка авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерүне, әйләнә-тирә мохитне саклауны, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен яңа редакциядә расларга (кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районы һәм Майская Горка авыл җирлеге рәсми сайтларында бастырып чыгарырга.

3. «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасына (РФ ТП ФДМС) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы — А.Р.Метшин